ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 508-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова, М.Х. Сәлахов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 508-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2299-VI ДС

508-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Зарипов,
Л.Н. Рыбакова,
М.Х. Сәлахов
тарафыннан кертелгән

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 2 өлешенә (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде.

2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 19 октябрендәге 503-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтләрен оптимальләштерү һәм федераль башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең төрле эшчәнлек өлкәләрендәге вәкаләтләре профильле вәкаләтле органнарга тапшырыла.

Шул исәптән «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законга мәдәни мирас объектларына мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру тәртибен билгеләүне, әлеге мәгълүмати язмаларны һәм билгеләрне карап тотуны федераль мәдәни мирас объектларын саклау органына йөкләү өлешендә үзгәрешләр кертелә.

Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертелергә тиеш.

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итми.